Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең
Кәләй торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
КАРАРЫ

23 ноябрь 2020 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2020 елның 10 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 11 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 12 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 13 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 16 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 17 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 18 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 19 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта, 2020 елның 20 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге: "Сез 2021 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлеге Кәләй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: юлларны норматив хәлгә китерү, урамнарны яктырту челтәрләрен норматив хәлгә китерү, Кәләй авылы территориясен төзекләндерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү, җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?" соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1417 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 731 кеше, бу 52% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 731 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Кәләй торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Кәләй авыл җирлегенең Кәләй авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2021 елда 400 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: юлларны норматив хәлгә китерү, урамнарны яктырту челтәрләрен норматив хәлгә китерү, Кәләй авылы территориясен төзекләндерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү, җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетысында бастырырга, Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Кәләй авылы, Специалистлар урамы, 2Д йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка

игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.Д. Нурзаринов